Республика Татарстан

Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

25.09.2024 Менделеевск ш. №559

«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү» проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының 2018 елның 2 августындагы 60 номерлы карары белән расланган нигезләмә нигезендә, Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 25 октябрендә 16 сәгатьтә Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының административ бинасында түбәндәге адрес буенча: Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 7 йорт, актлар залында "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү».проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:

Искаков А.Ф. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе;

Маштаков П.А.-«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы;

Хәбиров Р.З. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитекторы, комиссия секретаре;

Антоновская Н.И. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча).

3.2024 елның 25 сентябреннән башлап 2024 елның 25 октябренә кадәр «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге генераль планына үзгәрешләр кертү» проекты материаллары экспозициясен «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автономияле учреждениесенең баш архитекторы хезмәтендә: Менделеевск ш., Фомин ур., д19, 518 кабинет (5 кат). оештырырга

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 432650, Татарстан Республикасы, Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19 йорт («Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитекторы исеменә).

5.Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга http://Mendeleevsk.tatar.ru.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитекторы Р.З. Хәбировка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

Килештерелде
Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева